РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ СЕЛО-ЧУРИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
422125, РТ, Кукморский район,
с. Село-Чура, ул.Школьная д.34

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ ЧУРА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422125, РТ, Кукмара районы,
Югары Чура авылы, Мәктәп урамы, 34 йорт

тел.: (8 84364) 22-0-16, факс (8 84364) 22-0-16; e-mail:SChur.Kuk@tatar.ru

# КАРАР

31 июль, 2024 ел №27

Югары Чура авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Югары Чура авыл җирлеге Уставы нигезендә Югары Чура авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Кукмара муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Югары Чура авылы Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру мәсьәләсен карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

2. Кукмара муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Югары Чура авылы Башкарма комитетына:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Югары Чура авыл җирлеге бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр кертү хакында Югары Чура авыл җирлеге Советы карары проектын эшләргә һәм бюджет законнары нигезендә карауга тәкъдим итәргә.

http://kukmor.tatarstan.ru, Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый һәм финанс мәсьәләләре буенча комиссиягә йөкләргә.

Югары Чура авыл җирлеге
башлыгы урынбасары: А.Н.Афанасьев